# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Югары Тәкәнеш торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдаланумәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 8 «27» октябрь, 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчестатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пунктында 2022 елның «27» октябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнар кала, 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Югары Тәкәнеш торак пунктындагы җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;
- Югары Тәкәнеш торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Югары Тәкәнеш торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (сатып алу, иске су торбаларын алмаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыендакатнашучыла рисемлегенә 205 кеше кертелгән;
гражданнарҗыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 115 кеше, 56,1 % тәшкил итә:
Гражданнарҗыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүлендe:

«РИЗА» позициясе өчен 115 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен  0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныpга.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнар кала, 2023 елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Югары Тәкәнеш торак пунктындагы җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;
- Югары Тәкәнеш торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Югары Тәкәнеш торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (сатып алу, иске су торбаларын алмаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Җ.Хәмизуллин